КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 май г.Казань № 437

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2015 ел, 29 апрель, 299 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 671 нче; 2016 ел, 23 июнь, 429 нчы; 2016 ел, 23 сентябрь, 682 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 1000 нче; 2017 ел, 7 февраль, 62 нче; 2017 ел, 15 февраль, 88 нче; 2017 ел, 8 июнь, 362 нче; 2017 ел, 26 июнь, 436 нчы; 2017 ел, 22 декабрь, 1028 нче; 2017 ел, 25 декабрь, 1030 нчы; 2018 ел, 21 май, 383 нче; 2018 ел, 24 сентябрь, 842 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1182 нче; 2019 ел, 8 апрель, 275 нче; 2019 ел, 3 июнь, 464 нче; 2019 ел, 6 июнь, 476 нчы; 2019 ел, 20 сентябрь, 854 нче; 2020 ел, 27 гыйнвар, 24 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | Программа чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирә:<br>Татарстан Республикасында тулаем төбәк продуктының йөк сыйдырышлылык дәрәҗәсен 20 процентка киметергә;<br>норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өлешен 50 процентка кадәр арттырырга;<br>гомуми файдаланудагы элемтә юллары челтәренә кадәр каты өслекле юллары булган торак пунктларның чагыштырма авырлыгын 85,7 процентка кадәр арттырырга;<br>йөкләнешне исәпкә алып, төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларының һәм шәһәр агломерацияләрендә автомобиль юлларының тиешле норматив таләпләренә туры килә торган өлешен 53,7 процентка кадәр арттырырга;<br>шәһәр элемтәсенең маршрут челтәрен үстерү дәрәҗәсен 3,0 кадәр арттырырга;<br>шәһәрдән тыш элемтәнең маршрут челтәрен үстерү дәрәҗәсен 2,0 кадәр арттырырга;<br>пычраткыч зарарлы матдәләр ташлау һәм чыгару күләмен 10 процентка киметергә;<br>гомуми файдаланудагы транспорт көтүнең уртача интервалын 8,8 минутка кадәр киметергә»; |

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклау» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 2024 елга Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр:<br>норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өлеше – 50 процент;<br>гомуми файдаланудагы элемтә юллары челтәренә кадәр каты өслекле юллары булган торак пунктларның чагыштырма авырлыгы – 85,7 процент;<br>йөкләнешне исәпкә алып, төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларының һәм шәһәр агломерацияләрендә автомобиль юлларының тиешле норматив таләпләренә туры килә торган өлеше – 53,7 процент»; |

2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 нче таблица

«Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проектын тормышка ашыру кысаларында төбәк проекты күрсәткечләре

| Т\с | Исеме | Төп мәгънәсе | | Чоры, ел | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәгънәсе | датасы | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | I. «Юл челтәре» проекты күрсәткечләре | | | | | | | | | |
| 1. | Норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өлеше, % | 46,3 | 31.12.2017 | 46,4 | 46,9 | 47,5 | 48,2 | 48,8 | 49,4 | 50,0 |
| 2 | Шәһәр агломерацияләренең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | 72,5304 | 31.12.2017 | 78,6 | 80,4711 | 81,6202 | 82,5628 | 83,2513 | 84,0721 | 85 |
| 3. | Казан шәһәр агломерациясенең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | 74,7 | 31.12.2017 | 81,5 | 83,3 | 84 | 84,5 | 84,6 | 84,7 | 85 |
| 4. | Яр Чаллы шәһәр агломерациясенең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | 70,7 | 31.12.2017 | 76,7 | 78,7 | 80 | 81 | 82 | 83,5 | 85 |
| 5. | Түбән Кама шәһәр агломерациясенең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | 63,6 | 31.12.2017 | 65,7 | 67,2 | 70,8 | 74,4 | 78 | 81,6 | 85 |
| 6. | Юл челтәрендә юл-транспорт һәлакәтләре (авария-куркыныч участоклар) концентрациясе урыннары саны, % | 100 | 31.12.2017 | 88 | 84 | 76 | 68 | 60 | 52 | 50 |
| 7. | Машиналар артык күп йөрү режимында эшли торган федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өлеше, % | 3,93 | 31.12.2017 | 3,93 | 3,93 | 3,93 | 3,9 | 3,7 | 3,6 | 3,54 |
| | II. «Юл хуҗалыгын үстерүнең гомумсистема чаралары» проекты күрсәткечләре | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга яңа дәүләт контрактларының гомуми күләмендә Яңа һәм иң яхшы технологияләр, материаллар һәм яңадан куллануның технологик чишелешләре реестрына кертелгән яңа технологияләрне һәм материалларны файдалануны күздә тота торган илкүләм проекты кысаларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрактлар өлеше, % | 0 | 31.12.2018 | 0 | 10 | 20 | 40 | 53 | 66 | 80 |
| 2. | Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга яңа дәүләт контрактларының гомуми күләмендә бер контрактка юл эшләренең төрле төрләрен берләштерүне күздә тота торган тормыш циклы контрактлары принципларында эшләр башкаруны күздә тота торган илкүләм проекты кысаларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрактлар өлеше, % | 0 | 31.12.2018 | 0 | 10 | 20 | 35 | 50 | 60 | 70 |
| 3. | Автомобиль юлларында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерә торган стационар камералар саны, % | 100 | 31.12.2017 | 100 | 131 | 131 | 160 | 180 | 200 | 211 |
| | Автомобиль юлларында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерә торган стационар камералар саны, данә | 162 | 31.12.2018 | 100 | 212 | 212 | 259 | 292 | 324 | 342 |
| 4. | Татарстан Республикасы территория-сендә кертелгән интеллектуаль транспорт системалары саны, данә | 2 | 31.12.2017 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 4 |
| 5. | Габаритларны үлчәү буенча авто-матлаштырылган һәм урнаштырылган тикшерү пунктлары саны, данә | 2 | 31.12.2017 | 2 | 6 | 11 | 15 | 15 | 15 | 15"; |

1 нче ярдәмче программага теркәлгән 8 нче кушымтаның 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Төбәк проектының максаты һәм күрсәткечләре

| Т/с | Күрчәткеч | Күрчәт-кечнең тибы | База мәгънәсе | | Чоры, ел | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мәгънәсе | датасы | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | Норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмия-тендәге автомобиль юллары өлеше, % | төп | 46,3 | 31.12.2017 | 46,4 | 46,9 | 47,5 | 48,2 | 48,8 | 49,4 | 50 |
| 2. | Машиналар артык күп йөрү режимында эшли торган федераль һәм төбәк әһәмия-тендәге автомобиль юллары өлеше, % | төп | 3,93 | 31.12.2017 | 3,93 | 3,93 | 3,93 | 3,9 | 3,7 | 3,6 | 3,54 |
| 3. | Юл челтәрендә юл-транспорт һәлакәтләре (авария-куркы-ныч участоклар) концентра-циясе урыннары саны, % | төп | 100 | 31.12.2017 | 88 | 84 | 76 | 68 | 60 | 52 | 50 |
| 4. | Шәһәр агломерацияләренең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | төп | 72,5304 | 31.12.2017 | 78,6 | 80,4711 | 81,6202 | 82,5628 | 83,2513 | 84,0721 | 85 |
| 5. | Казан шәһәр агломерация-сенең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | төп | 74,7 | 31.12.2017 | 81,5 | 83,3 | 84 | 84,5 | 84,6 | 84,7 | 85 |
| 6. | Яр Чаллы шәһәр агломерация-сенең норматив торыштагы юл челтәре өлеше, % | төп | 70,7 | 31.12.2017 | 76,7 | 78,7 | 80 | 81 | 82 | 83,5 | 85 |
| 7. | Түбән Кама шәһәр агломера-циясенең норматив торыш-тагы юл челтәре өлеше, % | төп | 63,6 | 31.12.2017 | 65,7 | 67,2 | 70,8 | 74,4 | 78 | 81,6 | 85 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга яңа дәүләт контрактларының гомуми күләмендә Яңа һәм иң яхшы технологияләр, материаллар һәм яңадан кулланының технологик чишелешләре реестрына кертелгән яңа технологияләрне һәм материалларны файдалануны күздә тота торган илкүләм проекты кысаларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрактлар өлеше, % | төп | 0 | 31.12.2018 | 0 | 10 | 20 | 40 | 53 | 66 | 80 |
| 9. | Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга яңа дәүләт контрактларының гомуми күләмендә бер контрактка юл эшләренең төрле төрләрен берләштерүне күздә тота торган тормыш циклы контрактлары принципларында эшләр башкаруны күздә тота торган илкүләм проекты кысаларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрактлар өлеше, % | төп | 0 | 31.12.2018 | 0 | 10 | 20 | 35 | 50 | 60 | 70 |
| 10. | Автомобиль юлларында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерә торган стационар камералар саны, % | төп | 100 | 31.12.2017 | 100 | 131 | 131 | 160 | 180 | 200 | 211 |
| | Автомобиль юлларында юл | | 162 | 31.12.2018 | 100 | 212 | 212 | 259 | 292 | 324 | 342 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерә торган стационар камералар саны, данә | | | | | | | | | | |
| 11. | Татарстан Республикасы территориясендә кертелгән интеллектуаль транспорт системалары саны, данә | төп | 2 | 31.12.2017 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 4 |
| 12. | Габаритларны үлчәү буенча автоматлаштырылган һәм урнаштырылган тикшерү пунктлары саны (арта бара торган йомгак белән), данә | төп | 2 | 31.12.2017 | 4 | 6 | 11 | 15 | 15 | 15 | 15"; |

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасы транспорт комплексында дәүләт сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа паспортыннан соң:

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында гамәлгә ашырыла торган пассажирлар йөртүләрне оештыру турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ» сүзләрен «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ» сүзләренә алыштырырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«норматив таләпләргә туры килә торган төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары өлеше, процент»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«машиналарның күп йөрүләрен исәпкә алып, төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларының һәм шәһәр агломерацияләрендәге автомобиль юлларының тиешле норматив таләпләргә туры килә торган өлеше, процент».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин